Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советы

Пановка авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

17 ноябрь, 2025 ел № 4

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның Календарь планын раслау һәм гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Уставының 79 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен исәпкә алып кабул ителгән Татарстан Республикасы бюджет кодекслары нигезендә карар бирәм:

1. 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге бюджетын карауның һәм раслауның Календарь планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советының 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджеты хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга (алга таба - Совет карары проекты).

3. Билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пановка авыл җирлеге башкарма комитеты;

3.2. гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 1 декабре, 15.00 сәг;

3.3. гавами тыңлаулар урыны - Пановка ав., Школьная ур., 2А й., Пановка авылы мәдәният йортының тамаша залы;

3.4. авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән Совет карары проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган адрес - Пановка ав., Школьная ур., 2А й.

4. Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге башкарма комитетына:

4.1. билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

4.2. гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) Совет карары проектын тапшырырга.

4.3. 2025 елның 5 декабренә кадәр Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Пановка авылы, Школьная ур., 2А й. адресы буенча

урнашкан мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен урнаштырырга.

5. Советның карар проектын 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча Интернет челтәрендә Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев